| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«27» март 2023 ел № 283

Концессия килешүе төзүгә вәкаләтле
җирле үзидарә органын билгеләү турында

"Концессия килешүләре турында" 21.07.2005 № 115-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм " Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетын Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәренең җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектларына карата концессия килешүләре төзү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
2. Концессия килешүе төзү һәм аны гамәлгә ашыру өчен аукционда (конкурста) катнашуга әзерлек турында гаризаларны карау буенча эшче төркем булдыру.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Р.Г.Гиниятуллин

Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2023 елның 27 мартындагы
283 карарына 1нче кушымта

Концессия килешүе төзү һәм аны гамәлгә ашыру өчен аукционда (конкурста) катнашуга әзерлек турында гаризаларны карау буенча эшче төркем составы

1. комиссия рәисе — Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
2. комиссия секретаре – Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;

Комиссия әгъзалары:

3. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш бүлеге башлыгы;
4. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе (рәис вазыйфаларын башкаручы) (килешү буенча);
5. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе (рәис вазыйфаларын башкаручы) (килешү буенча).